**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНА БУЛЭК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«24» октябрь 2022 ел № 17

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яна Булэк авыл җирлеге Башлыгының «Тукай муниципаль районы Яна Булэк авыл җирлеге Куктэк Мирсэет авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2022 елның 17 октябрендәге 13 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Яна Булэк авыл җирлеге» уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яна Булэк авыл җирлеге Башлыгының «Тукай муниципаль районы Яна Булэк авыл җирлеге Куктэк Мирсэет авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2022 елның 17 октябрендәге 13 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С. Сагетдинов